| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ГЛАЗОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ГЛАЗОВО<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 27 октябре № 6

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Үрнәк-Күмәк авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм файдалану буенча гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1.Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Үрнәк-Күмәк авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 20 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Үрнәк-Күмәк авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

- авыл җирлеге чикләрендә юлларны карап тоту: юлларны кардан чистарту;
- ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту: зиратка контейнер сатып алу;
- җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру: Сабантуй бәйрәмен үткәрү;
- Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә, җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

су насосын алмаштыру;

җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү: минерализацияләнгән полосаны тезекләндерү;

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Үрнәк-Күмәк авылы, Мәктәп урамы, 3а йорт, Глазово авылы, Заречная урамы, 13, Петропавловка авылы, Горький урамы, 19а адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

«Глазово авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Н.К.Карабаева